ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.06.2020 п.г.т.Алексеевское № 219

**«2020 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 6 февралендәге 50 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Балачакны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру, 2020 елда мәктәп һәм студентлар каникуллары чорында аларның мәшгульлеген тәэмин итү өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2021 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 апрелендәге 305 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2021 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 07 февралендәге 73 номерлы карары белән

**карар кылам:**

1. «2020 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 06 февралендәге 50 номерлы карарына түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр кертергә:

1) «Хезмәтләр күләме расланган нормативлар нигезендә әлеге программа кысаларында үткәрелә торган чаралар» бүлегендәге карарга 1 нче кушымтада 3 пунктта

- «Үткәрү вакыты» баганасында «июнь-август» сүзләрен «июль-август» сүзләренә алмаштырырга,
- «Оештыру өчен җаваплы» дигән баганада «Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт һәм туризм бүлеге» сүзләрен «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы балалар-яшүсмерләр туризмы һәм экскурсияләр станциясе» ӨББ МБУ сүзләренә алмаштырырга;
- 4.1 пунктындагы карарга 2 нче кушымтада «Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт һәм туризм бүлеге» сүзләрен

«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы балалар-яшүсмерләр туризмы һәм экскурсияләр станциясе» ӨББ МБУ сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районы сайтында һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.В. Симашевага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К.Кадыйров**